ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.04.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 897**

Социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданының исәп-хисап нормасын һәм торак урыны мәйданын бирү нормасын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында торак урын мәйданының исәп-хисап алу нормасын билгеләргә, шуннан чыгып, гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, аларның торак урынының гомуми мәйданы гаиләнең бер әгъзасына 12 кв.метрдан да ким булмаган күләмдә, торак урыны белән тәэмин итү дәрәҗәсе билгеләнә.
2. Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә, социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданын бирү нормасын билгеләргә.
3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 сентябрендәге «Зеленодольск шәһәрендә торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын һәм торак урынны бирү нормасын билгеләү турында» 1830 нчы карарын үз көчен югалткан дип санарга.
5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 сентябрендәге «Зеленодольск шәһәрендә торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын һәм торак урын бирү нормасын билгеләү турында» 1830

номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 23 октябрендәге 2062 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга , Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев